| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.12.2018 Казан ш. № 10-116/кс

«ЖилКомСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2019 – 2023 елларга эчәргә яраклы суга һәм ташландык суны чыгаруга тарифлар билгеләү турында

"Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару турында" 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында" 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында" 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы «ЖилКомСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчәргә яраклы суга һәм ташландык суны чыгаруга тарифларны әлеге карарга 1 нче кушымтада каралган календарь бүленеш буенча билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2023 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы «ЖилКомСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2019 – 2023 елларга эчәргә яраклы суга һәм ташландык суны чыгаруга тарифларны җайга салуның озак вакытка каралган параметрларын әлеге карарга 2 нче кушымтада каралганча билгеләргә.

4. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы «ЖилКомСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә һәркем өчен ачык

булырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән дә соңга калмыйча ачарга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 5 декабрендәге 10-116/кс
номерлы карарына 1 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы «ЖилКомСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2019 – 2023 елларга, календарь бүленештә күрсәтеп, эчәргә яраклы суга һәм ташландык суны чыгаруга тарифлар

| № т/б | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме | Ел | Эчәргә яраклы суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Ташландык суны чыгаруга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | Апас муниципаль районы | | | |
| 1 | «ЖилКомСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 30 июненә кадәр | 26,09 | 34,37 |
| | | 2019 елның 1 июленнән алып 2019 елның 31 декабренә кадәр | 26,09 | 35,30 |
| | | 2020 елның 1 гыйнварыннан алып 2020 елның 30 июненә кадәр | 26,09 | 34,52 |
| | | 2020 елның 1 июленнән алып 2020 елның 31 декабренә кадәр | 27,49 | 34,52 |
| | | 2021 елның 1 гыйнварыннан алып | 27,49 | 34,52 |

| №<br>т/б | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме | Ел | Эчәргә яраклы суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Ташландык суны чыгаруга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | | 2021 елның 30 июненә кадәр | | |
| | | 2021 елның 1 июленнән алып 2021 елның 31 декабренә кадәр | 27,67 | 36,55 |
| | | 2022 елның 1 гыйнварыннан алып 2022 елның 30 июненә кадәр | 27,67 | 36,55 |
| | | 2022 елның 1 июленнән алып 2022 елның 31 декабренә кадәр | 29,12 | 36,61 |
| | | 2023 елның 1 гыйнварыннан алып 2023 елның 30 июненә кадәр | 29,12 | 36,61 |
| | | 2023 елның 1 июленнән алып 2023 елның 31 декабренә кадәр | 29,35 | 38,69 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге

Татарстан Республикасының Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 5 декабрендәге 10-116/кс
номерлы карарына 2 нче кушымта

## Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы «ЖилКомСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2019 – 2023 елларга эчәргә яраклы суга һәм ташландык суны чыгаруга тарифларны җайга салуның озак вакытка каралган параметрлары

| № т/б | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме, тариф төре | Ел | Операцион чыгымнарның нигез дәрәҗәсе | Операцион чыгымнарның нәтиҗәлелеге индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелек күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | су югалту дәрәҗәсе | электр энергиясенең чагыштырма кулланылышы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·сәг./куб.м |
| 1 | «ЖилКомСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | Эчәргә яраклы су | 2019 | 4383,46 | 1 | - | 1,3 | 2,13 |
| | | 2020 | 4487,18 | 1 | - | 1,3 | 2,13 |
| | | 2021 | 4620,00 | 1 | - | 1,3 | 2,13 |
| | | 2022 | 4756,75 | 1 | - | 1,3 | 2,13 |
| | | 2023 | 4897,55 | 1 | - | 1,3 | 2,13 |
| 1.2 | Ташландык суны чыгаруга тариф | 2019 | 1454,83 | 1 | - | - | 0,52 |
| | | 2020 | 1489,25 | 1 | - | - | 0,52 |
| | | 2021 | 1533,33 | 1 | - | - | 0,52 |

| № т/б | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме, тариф төре | Ел | Операцион чыгымнарның нигез дәрәҗәсе | Операцион чыгымнарның нәтиҗәлелеге индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелек күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | су югалту дәрәҗәсе | электр энергиясенең чагыштырма кулланылышы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·сәг./куб.м |
| | | 2022 | 1578,72 | 1 | - | - | 0,52 |
| | | 2023 | 1625,45 | 1 | - | - | 0,52 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге